Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Ульяновка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены карары

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлегенең Девичья Поляна авылы
торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**«17» октябрь 2025 ел** **№ 1/4**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 17 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең Девичья Поляна авылы территориясендә теркәлгән һәм дәими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәгеләрдән һәм 90 яшьтән өлкәнрәк булган гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (агачларны кисү, юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, Девичья Поляна торак пунктында кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы түләү, ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) урам күрсәткечләрен һәм йорт номерларын ясау һәм урнаштыру, Девичья Поляна торак пунктында аншлаглар урнаштыру һәм буяу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен башка билгеләнештәге җиһазларны ремонтлау (Девичья Поляна торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Девичья Поляна торак пунктындагы су җыю манарасы территориясен, скважиналарны

төзекләндерү, су насосларын сатып алу (ремонтлау), суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Девичья Поляна торак пунктында урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, 20-30 мм фракциясендәге вак таш сатып алу).

**«ӘЙЕ»** **«ЮК»**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 100 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 52 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 52 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Девичья Поляна авылы торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең Девичья Поляна авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәгеләрдән һәм 90 яшьтән өлкәнрәк булган гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (агачларны кисү, юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, Девичья Поляна торак пунктында кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы түләү, ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) урам күрсәткечләрен һәм йорт номерларын ясау һәм урнаштыру, Девичья Поляна торак пунктында аншлаглар урнаштыру һәм буяу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен башка билгеләнештәге җиһазларны ремонтлау (Девичья Поляна торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны

чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Девичья Поляна торак пунктындагы су җыю манарасы территориясен, скважиналарны төзекләндерү, су насосларын сатып алу (ремонтлау), суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Девичья Поляна торак пунктында урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, 20-30 мм фракциясендәге вак таш сатып алу) – карар кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Ульяновка авылы, Центральная урамы, 44 нче йорт, Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми интернет сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Ульяновка авыл җирлеге башлыгы С.З. Шәмсетдинов